.СОВЕТ
УТАР-АТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
*РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН*
ул.Кооперативная, д. 22, с. Утар-Аты,
Арский муниципальный район, 422017

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УТАР-АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Кооператив урамы, 22 йорт, Утар-Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422017

Тел. (84366)50-3-31, факс (84366)50-4-22. E-mail: Utat.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге башлыгы карары**

**22 март 2024 ел** **N 1**

**"Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар Аты авыл җирлегенең Утар Аты авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 2023 елның 21 ноябрнең 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлегенең Утар-Аты авылында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Арча муниципаль районы Утар Аты авыл җирлеге уставының 25 статьясына ярашлы рәвештә, Арча муниципаль районы Утар Аты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар Аты авыл җирлегенең Утар Аты авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 21 ноябрнең 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлегенең Утар-Аты авылында гражданнар җыенының беренче этабын Утар-Ата авылы, Кооператив урамы, 22 йорт адресы буенча 2024 елның 05 апрелендә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар Аты авыл җирлегенең Утар Аты авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 21 ноябрнең 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлегенең Утар-Аты авылында гражданнар җыенының икенче этабын Утар-Ата авылы, Кооператив урамы, 22 йорт адресы буенча 2024 елның 05 апрелендә 15 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3. Халык исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

1 нче этап: Кооператив урамы, Совет урамы, Комсомол урамы халкы

2 нче этап: 9 Май урамы, Мәктәп урамы халкы.

4. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар Аты авыл җирлегенең Утар Аты авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 21 ноябрнең 1 номерлы карарында гражданнар җыены соравын яңа редакциядә бәян итәргә:

“ Сез 2024 елда Утар Аты авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән 250 сум күләмендә үзара салым кертелүгә, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналаынр, ире яки хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итәргә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу, 9 Май урамы, Совет урамы, Кооператив урамы, Комсомол урамы, Мәктәп урамы буенча җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең йөрү өлешендә нигез һәм тигезләү катламнары җәю, Мәктәп урамыннан зиратка кадәр юл (300м); грейдер, каток хезмәтләре өчен түләү);

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (юл-урам челтәрендә сафтан чыккан яктырту приборларын алыштыру өчен яктырткычлар сатып алу);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (торак пункт территориясе һәм Аты елгасы ярындагы агач һәм куакларны санитар кисү һәм чыгару);

- янгынга каршы резервуарлар (янгынга каршы су җыю урыннары), янгын пирслары ясау, ремонтлау (Аты елгасында вакытлыча плотина ясау буенча эшләр башкару, бульдозер, амкадор хезмәтләре өчен түләү)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

5. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар Аты авыл җирлегенең Утар Аты авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 21 ноябрнең 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны ТР, Арча районы, Утар-Ата авылы, Кооператив урамы, 22 йорт адресы буенча мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan ru веб-адреслары буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Утар-Аты авыл җирлеге башлыгы Мөхәммәтгалиева А.Г.

СОВЕТ УТАР-АТЫНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1609012621